| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 27 март Баулы шәһәре № 205

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясе муниципаль хезмәте турында» 2007 елның 2 мартында кабул ителгән 25-ФЗ номерлы Федераль законның 9нчы статьясы һәм Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексының (25.06.2013 №50-ТРЗ) 8нче статьясы нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре турындагы нигезләмәне расларга.

2. Баулы муниципаль районы Советының 2014 елның 8 сентябрендә кабул ителгән «Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләрен билгеләү турында» 222нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин

АППАРАТ СОВЕТА
СОВЕТ АППАРАТЫ

Баулы муниципаль районы
Советының 27.03.2019
кабул ителгән
205 санлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре турындагы нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә, муниципаль хезмәткәрләрнең югары һөнәри хәзерлеген, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре бердәмлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификацион таләпләрне билгели.

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле квалификация таләпләре (алга таба - квалификация таләпләре) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кирәкле типик квалификация таләпләре (Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексының 8 статьясы 3нче бүлеге белән билгеләнгән) нигезендә эшләнде.

2. Квалификация таләпләренә туры килү муниципаль хезмәткә керү хакимияттә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен мәҗбүри шарт булып тора.

3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәгеләргә карата квалификацион таләпләр куела:

һөнәри белем дәрәҗәсенә;

муниципаль хезмәт стажына (дәүләт хезмәте, Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларын һәм муниципаль вазыйфаларны биләү) яисә вазыйфаны үтәү өчен кирәкле белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына (тәҗрибәгә), һөнәри белем һәм күнекмәләргә;

вазифаи бурычларны үтәү өчен кирәкле һөнәри белем һәм күнекмәләргә.

4. Һөнәри белем дәрәҗәсенә түбәндәге таләпләр куела:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: вазыйфаларның иң югары, төп һәм әйдәүче төркемнәре өчен югары белем булу мәҗбүри; өлкән һәм кече төркем вазыйфаларына – югары белем яисә урта һөнәри белем;

2) муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең иң югары вазифаларын биләү өчен – ике елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, юнәлеш буенча дүрт елдан да ким булмаган эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфаларын биләү өчен – бер елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, юнәлеш буенча ике елдан ким булмаган эш стажы.

5. Муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

1) муниципаль хезмәтнең иң югары вазыйфаларын биләү өчен – кимендә ике ел муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, юнәлеш буенча кимендә дүрт еллык эш стажы;

2) муниципаль хезмәтнең төп вазыйфаларын биләү өчен – бер елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, юнәлеш буенча ике елдан да ким булмаган эш стажы.

3) муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы, өлкән һәм кече вазыйфаларын биләү өчен – билгеләнмәгән.

6. Белгеч яки магистр дипломына ия затларга, диплом алган көннән өч ел дәвамында, муниципаль хезмәтнең төп вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек буенча эшләү стажына, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре билгеләнә – ярты елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча бер еллык эш стажына.

7. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белемгә һәм күнекмәләргә карата түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

- барлык вазыйфалар өчен: Россия Федерациясенең дәүләт телен – рус телен белү;

- муниципаль хезмәт вазыйфаларының иң югары һәм төп төркемнәрен биләү өчен Татарстан Республикасы дәүләт телләрен – рус һәм татар телләрен белү;

- барлык вазыйфалар өчен дә: Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль Законын; «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»"2007 елның 2 мартында кабул ителгән 25-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексын, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставын, эшчәнлек юнәлешенә караган норматив хокукый актларны, муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы, эш башкару һәм эшлекле аралашу нигезләрен, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне белү.

- барлык вазыйфалар өчен дә эшчәнлек юнәлешенә караган профессиональ күнекмәләр, шулай ук мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә күнекмәләр булу мәҗбүри булып тора.

7.1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарында барлык төркем муниципаль хезмәт вазыйфалары өчен дә һөнәри күнекмәләргә квалификация таләпләре булып эшне оештыра һәм планлаштыра белү, контрольдә тоту, кабул ителгән карарларның нәтиҗәләрен анализлау һәм

фаразлау, мәгълүмати технологияләрне белү, офис техникасыннан файдалану, документлар белән эш итү, коммуникация күнекмәләре тора.

7.2. Муниципаль хезмәтнең югары һәм төп вазыйфаларын башкару өчен кирәк булган һөнәри күнекмәләргә квалификация таләпләре: идарә итү эшчәнлеген җайга салу, идарә итү карарларын оператив кабул итү һәм гамәлгә ашыру, эшлекле сөйләшүләр алып бару һәм гавами чыгыш ясау, мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә күнекмәләргә ия булу: җирле үзидарә органнарында заманча мәгълүмат-коммуникация технологияләрен куллану мөмкинлекләрен һәм үзенчәлекләрен исәпкә алып, стратегик планлаштыру һәм төркем эшчәнлеге белән идарә итү, компьютерның эчке һәм тышкы җайланмалары белән эшләү, мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләре белән эшләү, шул исәптән Интернет челтәре белән эшләү, операцион системада эшләү, электрон почта белән эшләү, текст редакторында эшләү, электрон таблицалар белән эшләү, мәгълүмат базалары белән эшләү, проектлар белән идарә итү системалары белән эшләү. Идарә итү хезмәтенең асылын аңлау, әлеге хезмәтне оештыра, билгесезлек, рисклар шартларында карарлар (технологиктан алып стратегикка кадәр) кабул итә белү, идарә итү структурасын камилләштерә алу. Үз эшчәнлегенең хокукый нигезләрен, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең төп юнәлешләрен, оештыру-боеру документлары формаларын, документлар белән эшләү ысулларын регламентлаучы норматив документларны белү. Территорияне социаль-икътисадый үстерү юлларын, чараларын, ысулларын, хезмәттәшлекне оештыру күнекмәләрен белү;

7.3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфаларын биләү өчен кирәк булган һөнәри күнекмәләргә квалификация таләпләре булып үз эшчәнлек өлкәсе нигезләрен, бүлекчә функцияләрен, идарә итү методларын белү тора. Кул астында эшләүчеләрнең хокукларын, вәкаләтләрен һәм җаваплылыгын белү. Ведомство карамагындагы структураларның эшчәнлеген анализлау, идарәнең икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген билгели белү. Муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендәге түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиеш: компьютерның эчке һәм тышкы җайланмалары белән эшләү, мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләре белән эшләү, шул исәптән Интернет челтәре белән эшләү, операцион системада эшләү, электрон почта белән эшләү, текст редакторында эшләү, электрон таблицалар белән эшләү, презентацияләр әзерләү, электрон документларда график объектларны куллану, мәгълүматлар базалары белән эшләү.

7.4. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфаларын биләү, вазыйфаи бурычларын башкару өчен кирәкле һөнәри күнекмәләргә квалификация таләпләре: үз эшчәнлегенең хокукый нигезләрен, эш башкару нигезләрен белү, хезмәт белән бәйле документларны әзерли белү. Муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфаларын биләгән муниципаль хезмәткәрләр түбәндәге мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә күнекмәләргә ия булырга тиеш: компьютерның эчке һәм тышкы җайланмалары белән эшләү, мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләре белән эшләү, шул исәптән Интернет челтәре белән эшләү, операцион системада эшләү, электрон почта белән эшләү, текст

редакторында эшләү, электрон таблицалар белән эшләү, презентацияләр әзерләү, электрон документларда график объектларны куллану, мәгълүмат базалары белән эшләү.

7.5. Муниципаль хезмәтнең кече вазыйфаларын биләү, вазыйфаи бурычларын башкару өчен кирәкле һөнәри күнекмәләргә квалификация таләпләре: үз эшчәнлегенең хокукый нигезләрен, эш башкару нигезләрен белү.

8. Муниципаль хезмәтнең билгеле бер вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә квалификация таләпләре муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләрендә билгеләнә.